Россия Федерациясе
мөселманнары Диния нәзарәте

Россия Мөфтиләр шурасы

بسم الله الرحمن الرحيم

## МӨФТИ ШӘЕХ
## РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ
## ГЫЙД ӘЛ-ФИТР — УРАЗА БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
Һиҗри 1442 елның 1 нче шәүвәле
Милади 2021 елның 13 нче мае

بِسْــــــــمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

الحمد لله رب العالمين والعاقبة للمتقين

والصلاة والسلام على رسولنا محمد وعلى آله واصحابه اجمعين

Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм! Рәхмәте киң булган галәмнәрнең Хуҗасы, күк белән җирне бар кылучы, бар мәхлүкат тарафыннан данланучы Аллаһка мактау булсын! Пәйгамбәрләрнең һәм Рәсүлләрнең соңгысы Мөхәммәтﷺ салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучылар- га Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

***Кадерле дин кардәшләрем!***

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек,

Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм!

Сезне ихлас калебемнән һәм зур шатлык хисләре илә елның ике иң зур мөселман бәйрәмнәренең берсе — Гыйд Әл-Фитр — Ураза бәйрәме белән тәбрик итәм!

Изге Рамазан аен уразада, гыйбадәттә һәм игелекле гамәлләр кылып үткәрергә насыйп кылучы, сәламәт килеш һәм олуг дини бурычыбызны үтәп гаетне каршы алырга Үзенең рәхим-шәфкатен иңдергән Аллаһуга мактауларымны җиткерәм!

Рамазан бәрәкәте бар дөньяга иңде, Җәннәт капкалары ачылды, Җәһәннәм капкалары ябылды һәм шайтаннар богауланды. Раббыбыз Үзе кушканнарны үтәр өчен мөэминнәргә бар шартларны бирде. Бар дөнья мөселманнары, Раббыбызның чакыруына буйсынып, көндез уразада булды, төннәрне гыйбадәт белән күркәмләндерде, мәчетләрдә вә өйләрдә изге Коръән аятьләрен яңгыратты, догада булды.

الصيام لي وأنا أجزي به

**«Ураза Минем өчен һәм аңа әҗер-савабын да Үзем бирәм».**
(Бохари,1761; Мөслим, 1946),

Әлеге көдси хәдискә ияреп, без начарлык һәм әшәкелектән читләштек, күңелләребезне игелекле гамәлләр белән сафландырдык: ярлылар һәм мохтаҗлар турында кайгырттык, туганнарыбызга һәм якыннарыбызга ярдәм иттек, кардәшлек, туганлык җепләрен ныгыттык.

Аллаһның Рәсүле ﷺ:

مَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا
وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ

**«Иман белән һәм әҗерен Аллаһтан өмет итеп, Рамазан уразасын тотучының бар гөнаһлары гафу ителер»**, — дип әйткән (Бохари, 38; Мөслим, 760).

Шул ук вакытта Аллаһның яраткан колы безне Рамазанга салкын караудан кисәткән:

ويل لمن أدرك رمضان فلم يغفر له

**«Рамазан җиткәнен белеп тә, Аллаһның ярлыкавына ирешмәгән кешегә — кайгы»** (Сахих әт-тәргиб, 1679).

Бүген Рамазан төгәлләнде, без өммәтебез һәм якыннарыбыз белән бергә бәйрәм шатлыгын бүлешергә һәм фитр сәдакасын бирергә ашыгып, зарыгып көтелгән Гыйд Әл-Фитр көнен каршы алабыз!

***Кадерле дин кардәшләрем!***

Шиксез, быелгы Рамазан да, узган елгысы кебек үк, өммәтебез өчен җиңелләрдән булмады. Уразада килеш тә, миллионнарның сәламәтлегенә зыян салган, йөз меңнәрчә кешенең гомерен өзгән мәкерле вирус белән көрәшүне дәвам иттек. COVID-19 аркасында вафат булган дин кардәшләребезне шәһитләр дәрәҗәсенә күтәрүе һәм җәннәткә кертүе хакында Аллаһуга ялварабыз. Әмиин!

Рамазан — холкыбызны тәрбияләү, күңелләребезне затландыру ае. Быел без юмартлык, игелек, киң күңеллелек һәм фида кылуның гүзәл үрнәкләрен күрдек. Хәйриячеләр тарафыннан тормышка ашырыла торган ярдәм чаралары быел тагын да күбрәк мохтаҗларга иреште. Хөрмәтле дин кардәшебез Әбүсәид улы Сөләйман Кәримовның яхшылык үрнәгенә күп кардәшләребез кушылды. Һәркемнең хезмәте һәм фида кылган малы, бер бөртек кенә хәтле булган булса да, Галәмнәрнең Хуҗасы тарафыннан кабул ителүен һәм Кыямәт көнендә Уттан калкан булуын Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз. Галәмнәр Хуҗасы Аллаһу Раббыбыз Үзенең изге китабы Коръәни Кәримдә әйткәнчә:

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ

**«Бер бөртек хәтле изгелек кылган кеше дә аны күрәчәк»** [99:7].

Әлбәттә, Мәскәүдә һәм Россиянең кайбер шәһәрләрендә пандемия аркасында бәйрәм намазына җәмәгать белән бергә җыелу мөмкинчелеге юк. 2021 елда да күбебез барча мәхәлләбез, өммәтебез белән җыйналып, бәйрәм хисләребезне уртаклашудан мәхрүм. Бәйрәм рухын, бәйрәм күтәренкелеген без

өйләребездә гаилә әһелләребез белән генә уртаклашабыз. Бу хәлләр барчабызны борчуга салса да, Аллаһы Тәгаләнең сүзләре безгә юаныч булсын:

وَمَنْ أَحْيَاهَا فَكَأَنَّمَا أَحْيَا النَّاسَ جَمِيعًا

**«Кем дә кем бер кеше җанын сакласа, гүя бар кешелекне саклаган кебек булыр»** [5:32].

Бәйрәм көнендә мәчеткә бармавыбызның нигезле һәм җитди сәбәбендә безнең төп ниятебез — кеше гомерен саклау, яңа афәт һәм үлемгә сәбәпче булмау.

***Кадерле мөселманнар!***

Бәйрәм көнендәге догаларыбызда Галәмнәрнең Хуҗасыннан уразаларыбыз, гыйбадәтләребез, сәдакаларыбыз һәм бар игелекле гамәлләребезнең кабул булуын сорыйбыз! Туганлык, күршеләр белән дустанә мөнәсәбәтләр, бер-береңә хөрмәт хисләре, кешелеклелек сыйфатлары ныгыса иде дип догалар кылабыз. Раббыбыздан рәхмәт-мәгъфирәтен, рәхим-шәфкатен, ике дөнья бәхет-сәгадәтен сорыйбыз!

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөфтиләр шурасы исеменнән сезне: кадерле туганнарым, хөрмәтле ватандашларым һәм тугандаш илләрдә яшәүче дин кардәшләрем, Гыйд Әл-Фитр — Ураза бәйрәме белән тәбрик итәм. Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек, рәхимлек, бәхет һәм фани дөнья тормышында игелекле гамәлләрегездә ярдәмен бирүен телим! Әмиин!

*Вәссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!*

*Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм!*

*Мөфти шәех Равил Гайнетдин*
*Россия Федерациясе мөселманнары*
*Диния нәзарәте рәисе,*
*Россия мөфтиләр шурасы рәисе*